ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЕЛАБУЖСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ 26.09.2024 КАРАР
1477

2025 елга Алабуга муниципаль районында балаларга туристлык-туган якны өйрәнү, экология-биология, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисади, табигый-фәнни, техник һәм культурология юнәлешендә өстәмә белем бирү оешмаларының һәм балаларга өстәмә белем бирү буенча күппрофильле мәгариф оешмаларының норматив чыгымнарын раслау турында

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 1 өлешенең 11 пункты, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Балаларга өстәмә белем бирүче туристлык-туган якны өйрәнү, экология-биология, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм культурология юнәлешендәге мәгариф учреждениеләрен һәм балаларга өстәмә белем бирүче күппрофильле мәгариф учреждениеләрен финанслау нормативларын исәпләп чыгару тәртибе турында Нигезләмәне раслау хакында» 2009 елның 31 декабрендәге 939 номерлы карары, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Уставы нигезендә, Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. 2025 елга түбәндәгеләрне расларга:
1.1. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районында балаларга туристлык-туган якны өйрәнү, экология-биология, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм культурология юнәлешендә өстәмә белем бирү оешмаларында һәм балаларга өстәмә белем бирү буенча күппрофильле мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыруга норматив чыгымнарны (1 нче кушымта).

1.2. Балаларга туристлык-туган якны өйрәнү, экология-биология, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм культурология юнәлешендә өстәмә белем бирү оешмаларында һәмбалаларга өстәмә белем бирү буенча күппрофильле мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыру өчен норматив чыгымнарга төзәтү коэффициентын 0,75 күләмендә.

2. Алабуга муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:
2.1. Әлеге карарның 1 пунктында балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларын әлеге карарның 1 пунктында расланган балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларының норматив чыгымнары нигезендә финанслауны;
2.2. Әлеге карарның 1 пунктында расланган балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларының норматив чыгымнары гамәлдә булу чоры дәвамындахезмәт законнарында һәм башка норматив хокукый актларда билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла торган балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт хакын индексацияләү белән бергә яңадан карауны тәэмин итәргә.
3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2025 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Н.Д. Курамшинга йөкләргә.

Җитәкче вазифаларын башкаручы А.А. Томилин

Татарстан Республикасы
Алабуга муниципаль районы
Башкарма комитетының
1477
26.09.2024ел
карарына 1 нче кушымта

**2025 елга Алабуга муниципаль районында балаларга туристлык-туган якны өйрәнү, экология-биология, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисади, табигый-фәнни, техник һәм культурология юнәлешендә өстәмә белем бирү оешмаларының һәм балаларга өстәмә белем бирү буенча күппрофильле мәгариф оешмаларының норматив чыгымнары**

| Өстәмә белем бирү программасының юнәлеше | Территориаль урнашу | Норматив чыгымнар, 1 укучыга бер елга, сумнарда | | |
|---|---|---|---|---|
| | | белем алуның беренче елы | белем алуның икенче елы | белем алуның өченче һәм аннан соңгы еллары |
| Сәнгать-эстетик | шәһәр җирлеге | 8 280 | 15333 | 18399 |
| | авыл җирлеге | 8680 | 16074 | 19289 |
| Физкультура-спорт | шәһәр җирлеге | 8179 | 15145 | 18174 |
| | авыл җирлеге | 8 579 | 15887 | 19064 |
| Техник иҗат | шәһәр җирлеге | 8583 | 15895 | 19074 |
| | авыл җирлеге | 8984 | 16636 | 19963 |
| Туристлык-туган төбәкне өйрәнү | шәһәр җирлеге | 8381 | 15520 | 18624 |
| | авыл җирлеге | 8781 | 16261 | 19514 |
| Эколого-биологик | шәһәр җирлеге | 8381 | 15520 | 18624 |
| | авыл җирлеге | 8781 | 16261 | 19514 |
| Хәрби-патриотик | шәһәр җирлеге | 8381 | 15520 | 18624 |
| | авыл җирлеге | 8781 | 16261 | 19514 |
| Социаль-педагогик | шәһәр җирлеге | 7976 | 14771 | 17725 |
| | авыл җирлеге | 8376 | 15512 | 18614 |
| Социаль - икътисади | шәһәр җирлеге | 7976 | 14771 | 17725 |
| | авыл җирлеге | 8376 | 15512 | 18614 |
| Табигый-фәнни | шәһәр җирлеге | 8381 | 15520 | 18624 |
| | авыл җирлеге | 8781 | 16261 | 19514 |